**СОВЕТ**
**Азевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Азево авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.07.2020 Азево авылы № 60-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 гыйнварындагы 47-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Азево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы нигезендә, муниципаль хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 гыйнварындагы 47-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Азево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 бүлектә 12.1 пунктындагы 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиленең рөхсәте белән коммерцияле булмаган оешма идарәсендә (сәяси партия

белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;».

1.2. 12 бүлек 12.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.1.) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;».

1.3. 26 бүлектә 26.2 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе В.С. СЕМЕНОВ